ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
КАРАР

№ 2 10 ноябрь 2025 ел

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге
Мюд авылында гражданнарның үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР бирәм:

1. 2025 елның 19 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы, Мюд авылы, Үзәк урам, 35-нче йорт адресы буенча мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Мюд авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

* Мюд торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юллары чокырларын ремонтлау, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

**Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

* Мюд торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияләрне чабу ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)

* **Мюд торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)**

• Торак пункт чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (шартнамә буенча товарлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыела торган урыннарына, стендларга һәм такталарга белдерү элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районы «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина